**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татар халкының «Сабантуй» бәйрәмен уздыру турында**

«Татарстан Республикасының бәйрәм көннәре һәм истәлекле даталары турында» 1992 елның 19 февралендәге 1448-XII номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы нигезендә **карар бирәм:**

1. 2020 елның 4 июлен татар халкының «Сабантуй» бәйрәмен уздыру көне дип билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыклары белән бергәләп, татар халкының «Сабантуй» бәйрәменә багышланган чараларны Татарстан Республикасы территориясендә яңа коронавирус инфекциясе таралу куркынычы белән бәйле рәвештә кертелгән чикләү чараларын үтәү тәэмин ителә торган рәвештә уздыруны оештырырга.

3. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына татар халкының «Сабантуй» бәйрәменә багышланган чараларны массакүләм мәгълүмат чараларында яктыртуны оештырырга.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 29 июнь
№ ПУ-371